# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Митрәй торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

**№ 2** **13 ноябрь 2024 ел.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Митрәй торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Митрәй торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгәннәрдән тыш, үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

1) Митрәй торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирүне (материал, җайланмалар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алмаштыру, муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

- (Митрәй торак пунктында Яшьләр ур., Тукай ур., Тау асты ур., Мәктәп ур. буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш түшәлгән юлларны төзү һәм ремонтлау, вак ташу, эшләр һәм муниципаль контракт буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;
- (Митрәй торак пунктында юлларны кардан чистарту, муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- Азнакай районы, Митрәй торак пункты, Тукай урамы, 15А.
- әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Халык җыенында рәислек итүче,
Әсәй авыл җирлеге Башлыгы Г.З. Дәминова